ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30 июнь 2014 ел Казан шәһәре № 3-4/э

***Татарстан Республикасы җирендәге челтәр оешмалары арасында электр энергиясен тапшыру хезмәтен башкару вакытында үзара хисап тоту индивидуаль тарифларына үзгәрешләр кертү турында***

Россия Федерациясе Хөкүмәте “Электр челтәренә технологик тоташтыру өчен челтәр оешмаларына кергән керемне компенсацияләү хакындагы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм тариф карарларын кабул итү турында” 11.06.2014 № 542 карарын тормышка ашыру максатыннан, 15.06.2010 №468 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты кагыйдәнамәсе нигезендә, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы челтәр оешмалары арасында электр энергиясен тапшыру хезмәтен башкару вакытында үзара хисап тоту индивидуаль тарифларын яңадан карап чыгып, КАРАР чыгарды:

1. Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнгән, Татарстан Республикасы челтәр оешмалары арасында электр энергиясен тапшыру хезмәтен башкару вакытында үзара хисап тоту индивидуаль тарифларын үзгәрешсез калдырырга:

- 14.12.2012 № 3-11/э “Татарстан Республикасы ҖЧҖ “Энерготехснаб” һәм ААҖ “Челтәр компаниясе” челтәр оешмалары арасында электр энергиясен тапшыру хезмәтен башкару вакытында үзара хисап тоту индивидуаль тарифларын билгеләү турында” карарын;
- 14.12.2012 № 3-12/э “Татарстан Республикасы челтәр оешмалары арасында электр энергиясен тапшыру хезмәтен башкару вакытында үзара хисап тоту индивидуаль тарифларын билгеләү турында” карарын;
- 25.12.2012 № 3-19/э “Татарстан Республикасы ААҖ “Нижнекамскнефтехим” һәм ААҖ “Челтәр компаниясе” челтәр оешмалары арасында электр энергиясен тапшыру хезмәтен башкару вакытында үзара хисап тоту индивидуаль тарифларын билгеләү турында” карарын;
- 22.11.2013 № 3-7/э Татарстан Республикасы ААҖ “ТАНЕКО” һәм ААҖ “Челтәр компаниясе” челтәр оешмалары арасында электр энергиясен тапшыру хезмәтен башкару вакытында үзара хисап тоту индивидуаль тарифларын билгеләү турында” карарын;

- 13.12.2013 № 3-10/э “Татарстан Республикасы ҖЧЖ “ТранснефтьЭлектроСетьсервис” һәм ААҖ “Челтәр компаниясе” челтәр оешмалары арасында электр энергиясен тапшыру хезмәтен башкару вакытында үзара хисап тоту индивидуаль тарифларын билгеләү турында” карарын;

- 13.12.2013 № 3-12/э “Татарстан Республикасы ААҖ “Казан моторлар төзү җитештерү берләшмәсе” һәм ААҖ “Челтәр компаниясе” челтәр оешмалары арасында электр энергиясен тапшыру хезмәтен башкару вакытында үзара хисап тоту индивидуаль тарифларын билгеләү турында” карарын;

- 18.04.2014 № 3-1/э “Татарстан Республикасы ААҖ “Казэнерго” һәм ААҖ “Челтәр компаниясе” челтәр оешмалары арасында электр энергиясен тапшыру хезмәтен башкару вакытында үзара хисап тоту индивидуаль тарифларын билгеләү турында” карарын;

- 30.05.2014 № 3-3/э “Татарстан Республикасы ААҖ “Азнакай җылылык челтәре предприятиясе” һәм ААҖ “Челтәр компаниясе” челтәр оешмалары арасында электр энергиясен тапшыру хезмәтен башкару вакытында үзара хисап тоту индивидуаль тарифларын билгеләү турында” карарын.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
тарифлар буенча
Дәүләт комитеты рәисе
вазыйфаларын башкаручы А.Л. Штром